**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 30 гыйнварындагы 288 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 612 кв.м;
- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номерлары – 16:16:120132:216;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы;
- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: вакыты чикләнмәгән;

1.2. гариза бирүче: «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесе;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 30 гыйнварындагы
288 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре




| | |
|---|---|
| Масштаб: 1:1500<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:16:0132 | кадастр кварталы |
| 16:16:120132:216 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең |

______________________________